# 5 нче сыйныфта татар теле





# кыш

# җәй

**Бу сүзләр бер –берсенә нинди мәгънәдә кулланылган?**

- Кыш салкын, ә җәй җылы .



- Кышкы көн кыска, ә җәйге көн озын .

- Кышын табигать йокыга тала, җәен уяна



***Кыш*** – ***җәй***

***Салкын*** – ***җылы***

***Кыска*** – ***озын***

***Йокыга тала*** - ***уяна***

# <u>Антонимнар</u>

# Антонимнар – капма-каршы мәгънәле сүзләр

*Антоним- грек сүзе,каршы мәгънәсендә*

***Антонимнар парлашып килеп, парлы сүз ясый.***

***Парлы сүз составындагы сүзләр берүк сүз төркеменнән була.***


*Бу бәйрәмгә **олысы-кечесе** җыелды.*

*Базарда **алыш-биреш** күп булды.*





# Болар антонимнармы?



***Кара*** ***җиргә*** ***ак*** ***кар*** ***ява.***

***Ак*** ***йөзең сагыштан*** ***сары*** ***булды.***


***Антонимнар***, шартлы рәвештә, ***даими*** һәм ***очраклы*** антонимнарга бүленә. *Даими антонимнар* контексттан тыш та антоним буларак кабул ителә. М-н: ***бар-юк, ата-ана*, *көн-төн*** һ.б. Ә *очраклы антонимнар* сүзтезмә, җөмлә яисә текст эчендә генә капма-каршы мәгънә ала.

М-н:

***Әни назлап ышандыра,***
***Әти-кырыслык белән...***
***Нәтиҗәгә ирешәбез***
***Минем тырышлык белән.***

(Ш.Галиев)

# АНТОНИМНАР
# НИ ӨЧЕН
# КУЛЛАНЫЛА ?



**Кара - ак**

**Зур - кечкенә**

***Чагыштыру һәм капма- каршы кую***

Күп **исле** гөлләр арасында
Бер **иссез** гөл исле булган.
Күп иссез гөл арасында
Бер исле гөл иссез калган.

*Сүзлек хәзинәсен баета, сөйләмнең сәнгатьлелеген көчәйтә*

# Биремнәр эшләү

# Рәсемнәрдә антонимнарны табыгыз










# Антонимнар яз

| | |
|---|---|
| Ачы | тәмле |
| Уңган | ялкау |
| Башлау | тәмамлау |
| Кыска | озын |
| Якты | караңгы |
| Туры | кыек |
| Табу | югалту |
| Дус | дошман |
| Аз | күп |
| Кичә | бүген |



# Антонимнар куеп мәкальләрнең ахырын язып бетерегез

1. Иң ачы нәрсә дә тел, иң ...

2. Кыю бер үләр, ...

3. Яхшы тел яз кебек, ...

4. Картлар сүзен капчыкка сал, ... .

# Тикшерәбез

1. Иң ачы нәрсә дә тел, иң татлы нәрсә дә тел.
2. Кыю бер үләр, куркак мең үләр.

3. Яхшы тел яз кебек, яман тел көз кебек.

4. Картлар сүзен капчыкка сал, яшьләр сүзен янчыкка сал.




# Антонимнарны табыгыз

1. *Хан җыены – зур табын-*
   ***Бер шаулады , бер тынды,***
   ***Туктамыштай олы хан***
   ***Бер утырды, бер торды. (“Идегәй” дастаныннан)***

2. ***Көне буе караса да,***
   ***Көзгедән бер дә туймый.***
   ***Чәчләрен әле тегеләй.***
   ***Әле болайга тарый.***

3. ***Бар иде, ди, юк иде, ди***
   ***Ач иде,  ди , тук иде, ди***
   ***Бер авылда бер агай. ( Такмаза)***



# *Антонимнарны табып, төрен билгеләгез*

1. Әти кеше кап-кара мыегы астыннан ап-ак тешләрен ялтыратып елмайды.

2. Мин ул кичергән кыенлыкларның, яхшы яки хата эшләренең, шатлык- хәсрәтләренең күбесен белмидер, шәт.

3. Алай да кайсысы чукыды соң әле күгәрченнәрнең? Анасымы, әллә атасымы?

4. Ата-ананы тыңлаган – адәм, тыңламаган әрәм булган.

# Өйгә эш




«Кышкы табигать» темасына антонимнар кулланып, миниатюр сочинение язып килергә

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

